ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**03.12.2021**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 3088**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 04 октябрендәге «Җәмәгать транспорты хезмәтләренең электрон бердәм исемле социаль йөртү билетлары буенча гражданнарның аерым категорияләрен йөртүдән һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле алынып бетмәгән керемнәрне каплау максатларында, оешмаларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 2417 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә аерым категориядәге гражданнар өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 19 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында айлык бердәм социаль юл билетын һәм айлык бердәм балалар социаль юл билетын бирү тәртибен раслау турында» 2005 елның 07 апрелендәге 161 номерлы карарына , Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетларыннан субвенцияләр бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 20 март, 210 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетларына субвенцияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 23 сентябрендәге 908 номерлы карарына туры китереп, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Җәмәгать транспорты хезмәтләренең электрон бердәм исемле социаль йөртү билетлары

буенча гражданнарның аерым категорияләрен йөртүдән һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле алынып бетмәгән керемнәрне каплау максатларында оешмаларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарының төзәтмәләр проектына Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы контроль-хисап палатасының 2021елның 04 октябрендәге 350 номерлы бәяләмәсе нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 04 октябрендәге «Җәмәгать транспорты хезмәтләренең электрон бердәм исемле социаль йөртү билетлары буенча гражданнарның аерым категорияләрен йөртүдән һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле алынып бетмәгән керемнәрне каплау максатларында оешмаларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәнераслау хакында»гы 2417 номерлы карарына (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3.2 пунктындагы дүртенче абзацны, бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«К(тр.орг)рег- хисап аена тиешле муниципаль берәмлек территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны җайга сала торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен йөрү билеты һәм (яисә) балалар юл йөрү билеты буенча хезмәт күрсәтүләр күрсәтүгә бәйле рәвештә муниципаль берәмлектә транспорт оешмасының алынмаган керемнәрен компенсацияләү күләме (алга таба - алынмаган керемнәрне компенсацияләү күләме) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

К(тр.орг)рег = (SUM (Tгорji x Прегjit) + (Tпрi x Ррегit)) – Воргit.»

1.2. Нигезләмәнең 3.2 пунктындагы егерме алтынчы абзацны, егерме җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«К(тр.орг)нерег-хисап аенда тиешле муниципаль берәмлек территориясендә пассажирлар йөртүне җайга салынмый торган тарифлар буенча даими рәвештә гамәлгә ашырганда алынмаган керемнәрнең компенсациясе күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

К(тр.орг)нерег = (SUM (Nгорji x Пнерегjit) + (Nпрi x Рнерегit)) – Воргit»

1.3. Нигезләмәнең 4.1 пунктындагы 18 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18) фактта башкарылган чыгымнарны (алынмаган керемнәрне) раслаучы документлар: «Социаль карта» акционер җәмгыятенең хисаплары.

1.4. Нигезләмәнең 4.2 пунктындагы өченче абзацында, җиденче абзацында, сигезенче абзацында «10 (ун) эш көне эчендә» сүзләрен «5 (биш) эш көне эчендә»сүзләренә алмаштырырга;

4.2 пунктның тугызынчы абзацында «10 (ун) эш көне эчендә» сүзләрен «3 (өч) эш көне эчендә»сүзләренә алмаштырырга.

2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 04 октябрендәге 2417 номерлы карары белән расланган Җәмәгать транспорты хезмәтләренең электрон бердәм исемле социаль йөртү билетлары буенча гражданнарның аерым категорияләрен йөртүдән һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле алынып бетмәгән керемнәрне каплау максатларында оешмаларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы

бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 бүлек «Йомгаклау нигезләмәләр»енең Субсидия бирү турындагы килешүнең 6.2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«6.2. Әлеге килешү якларның үзара ризалыгы буенча үзгәртелергә яки тулыландырылырга мөмкин. Әлеге килешүгә теләсә нинди үзгәрешләр һәм өстәмәләр аларны язма рәвештә беркеткән һәм ике як тарафыннан имзаланган очракта гына дөрес.

Баш күрсәтмә бирүчегә (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты) элек төзелгән килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкинлеге булмауга китерә торган тиешле финанс елына (тиешле финанс елына һәм план чорына) субсидияләр бирү өчен бюджет йөкләмәләренең элек бирелгән лимитларын алучы буларак кимегән очракта, якларның үзара ризалыгы буенча өстәмә килешү төзелә, яңа шартлар буенча ризалыкка ирешмәгәндә, килешү өзелә (килешүне өзү турында килешү төзелә)».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигына интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары З.Ф. Хәбибуллинга йөкләргә.

Җитәкче И. Р. Ганиев